Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге

Пимәр авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

14 июнь, 2018 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.

Пимәр авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау, ачыклау һәм исәпкә алу максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча халык алдында тыңлаулар үткәрүне 2018 елның 16 июленә 10.00 сәгатьтә билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү урыны итеп - Пимәр мәдәният йорты залын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Пимери авылы, Совет урамы, 25а йорт.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына тәкъдимнәрне һәм өстәмәләрне исәпкә алуның түбәндәге тәртибен билгеләргә, шулай ук гавами тыңлауларда катнашу өчен түбәндәге чыгышлар хокукы белән гариза бирергә:

- язма рәвештә, көн саен (эш көннәрендә) 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр (2018 елның 9 июлендә) Пимәр авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: Пимәр авылы, Совет урамы, 34а йорт, гражданнар өчен мәҗбүри күрсәтелгәнчә: фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, яшәү урынын теркәү адресы, эш урыны һәм биләгән вазыйфасы, контактлы телефоннар.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адрес буенча муниципаль хокукый актлар текстларын урнаштыру өчен мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов